СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 с. Печищи № 41-200

Печище авыл җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчалары кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 28.07.2004 № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы, «Печищи авыл җирлегенең 2018 елның 20 сентябрендәге 40-197 номерлы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Печищи авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 20 сентябрендәге 40-197 карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Печищи авыл җирлеге уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Печищи авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 150 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә рөхсәтегез бармы:

- Печищи авылында урамнарны яктырту системасын ремонтлау

ӘЙЕ ЮК"

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Печище авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы Л. В. Яковлев